РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2019 елның 23 нче октябре** **Чистай шәһәре** **№40/5**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәр Советының
2019 елның 11 июнендәге
“Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
“Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегендә
муниципаль хезмәт турында”гы 35/2 нче карарына
үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законына таянып, Муниципаль хезмәт турындагы Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

**Карар бирә:**

1. “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында”гы 2019 елның 11 июнендәге 35/2 нче номерлы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә, 13 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль хезмәткә кергәндә гражданин тәкъдим итә:

1) муниципаль хезмәткә керү һәм муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүне сорап язма гариза;

2) үз кулы белән тутырылган һәм Россия Федерациясе гражданины имзасы белән, фотосын теркәп, билгеләнгән формадагы анкета;

3) паспорт һәм граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык;

4) хезмәт кенәгәсе (контракт) беренче тапкыр төзелмәсә, хезмәт кенәгәсе;

5)белеме һәм квалификациясе турында документлар, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне, яки квалификация алуны раслаучы документлар, гыйльми дәрәҗә бирү турында, гыйльми исем алуны раслаучы документлар (әгәр бар икән);

6) Россия Федерациясе дәүләт бүләкләре, Россия Федерациясе Президентының Мактау грамотасы белән бүләкләү турындагы карарларның күчермәләре, Россия Федерациясе Президентының рәхмәт хаты, мактаулы,

хәрби һәм махсус исемнәр бирү, дәүләт премияләре (әгәр андыйлар булса) бирү турындагы мәгълүмат;

7) хәрби исәпкә алу документлары (хәрби бурычлылар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен);

8) муниципаль хезмәткә кергән елга кадәр һәм агымдагы елны кертеп үзенең, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

9) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында теркәлүне раслый торган документ;

10) Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча физик затның салым органында исәпкә куелуы турында таныклык;

11) гражданнарның мәҗбүри медицина иминияте медицина полисы;

12) гражданның муниципаль хезмәткә урнашуга, яки аны узуга комачаулаучы авыруның булмавын дәлилләүче билгеләнгән формадагы медицина бәяләмәсе.

13) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждан “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгълүмат урнаштырган һәр сайтның адресын һәм шулай ук өч календарь ел эчендә аларны билгеләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар.”.

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны, Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә О.В. Добронравовага йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәр башлыгы Д.А. Иванов